| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ШӘЙМОРЗА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

---

**Иске Шәйморза авылы**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 февраль 2018 ел № 30/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының «җир салымы турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы, Россия Федерациясе Салым кодексына туры китерү максатыннан чыгып, карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» 2017 елның 16 октябрендәге 25/2 номерлы карарына, 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Салым түләүчеләр - салым ташламалары хокукына ия физик затлар, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калуы рәвешендә салым органына үз теләге белән салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.».

2. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

3. Иске Шәйморза авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Иске Шәйморза авыл җирлеге сайтында әлеге карарны урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгару.

Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы Чүпрәле муниципаль районы Татарстан Республикасы: И.С.Бикчуров